| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь 2022 ел № 160

**Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларга аренда түләве буенча ташламалар бирү турында**

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларга аренда түләве буенча ташламалар бирү турында» 2022 елның 16 ноябрендәге 2507-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә, Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль казнасын тәшкил иткән, арендага физик затлар, шул исәптән шәхси эшкуарлар, бер үк физик зат юридик затның бердәнбер оештыручысы (анда катнашучы) һәм аның җитәкчесе булган физик затлар (әгәр әлеге физик затлар, шул исәптән шәхси эшкуарлар, бер үк физик зат юридик затның бердәнбер оештыручысы (анда катнашучы) һәм аның җитәкчесе булган юридик затлар «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә алга яисә «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба - Федераль закон) 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт уза торган яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән булса) алган мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендага алу шартнамәләре буенча түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен кичектереп торуны (алга таба - аренда түләвен кичектереп тору);

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәләрен өзү мөмкинлеген.

2. Әлеге карарның 1 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен кичектереп тору түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән зат тарафыннан аренда түләвен кичектереп тору чорында шартнамә буенча арендалана торган мөлкәттән файдаланмау;

арендага алучы, шул исәптән ышанычлы затлар аша, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу статусын раслый торган документларның күчермәләрен яисә Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә хәрби хезмәт узу турында контракт яки Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзү хакында хәбәрнамә күчермәләрен теркәп, арендага бирүчегә әлеге контрактлар төзелгән башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан бирелгән аренда түләвен кичектереп тору турында хәбәрнамә җибәрә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән арендага алучыга әлеге карарның 4 пункты нигезендә исәпләнә торган чорга аренда түләве кичектереп торыла;

аренда түләве буенча бурыч аренда түләвен кичектереп тору чоры тәмамланган көннән аренда шартнамәсенә теркәлгән өстәмә килешү нигезендә этаплап, айга иң күбе бер тапкыр, тигез түләүләр белән түләнергә тиеш, аның күләме аренда шартнамәсе буенча ай саен түләнә торган аренда түләве күләменең яртысыннан артмаска тиеш;

аренда түләвен кичектереп торуга бәйле рәвештә, арендага алучы тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорда арендага алучы тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибе һәм сроклары үтәмәүгә бәйле рәвештә, штрафлар, чит кеше акчасын файдаланган өчен процентлар яисә башка җаваплылык чаралары (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кулланылмый.

3. Әлеге карарның 1 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәсен өзү түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

арендага алучы, шул исәптән ышанычлы затлар аша, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу статусын раслый торган документларның күчермәләрен яисә Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә хәрби хезмәт узу турында контракт яки Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзү хакында хәбәрнамә күчермәләрен теркәп, арендага бирүчегә әлеге контрактлар төзелгән башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан бирелгән аренда түләвен кичектереп тору турында хәбәрнамә җибәрә;

аренда шартнамәсе арендага бирүче аренда шартнамәсен өзү турында хәбәрнамә алган көннән соң өзелергә тиеш;

аренда шартнамәсен өзүгә бәйле рәвештә, штрафлар, чит кеше акчасын файдаланган өчен процентлар яисә башка җаваплылык чаралары (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кулланылмый.

4. Аренда түләвен кичектереп тору вакыты 90 көнгә озайтылган мобилизация срогы буларак исәпләп чыгарыла һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән зат мобилизация чорында бурычларны башкарганда алган имгәнүне (җәрәхәтләнүне, травманы, контузияне) яисә авыруны дәвалау өчен

стационар шартларда хастаханәләрдә, госпитальләрдә, башка медицина оешмаларында булган чорга, шулай ук әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән зат хәбәрсез югалган дип танылган очракта, шулай ук аны хәбәрсез югалган дип тану турында суд карары гамәлдән чыкканга кадәр яисә суд тарафыннан аны үлгән дип игълан итүгә кадәр чорда озайтыла.

Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән зат һәлак булган (вафат булган) очракта, әгәр ул мобилизация чорында яисә әлеге чордан соң, әмма мобилизация чорында алынган имгәнү (җәрәхәтләнү, травма, контузия) яисә авыру аркасында үлгән (вафат булган) булса, шулай ук аны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә I төркем инвалиды дип таныган очракта, кичектереп тору чоры өчен аренда түләве алынмый.

Үлемгә яки Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә I төркем инвалиды дип тануга китергән имгәнүнең (җәрәхәтләнүнең, травманың, контузиянең) яисә мобилизация чоры белән сәбәпле бәйләнеше хәрби табиблар комиссияләре һәм (яисә) медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан билгеләнә.

5. Хуҗалык алып бару хокукында яисә муниципаль предприятиеләр белән оператив идарә итү хокукында яисә муниципаль учреждениеләр белән оператив идарә итү хокукында, арендага алучылары булып физик затлар, шул исәптән шәхси эшкуарлар, бер үк физик зат юридик затның бердәнбер оештыручысы (анда катнашучы) һәм аның җитәкчесе булган физик затлар торган (әгәр әлеге физик затлар, шул исәптән шәхси эшкуарлар, бер үк физик зат юридик затның бердәнбер оештыручысы (анда катнашучы) һәм аның җитәкчесе булган юридик затлар «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә алга яисә Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт уза торган яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән булса) муниципаль мөлкәтне арендага алу шартнамәләре буенча муниципаль оешмаларга һәм муниципаль учреждениеләргә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен кичектереп торуны;

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәләрен өзү мөмкинлеген.

6. Әлеге карарның 5 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен кичектереп тору әлеге карарның 2 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге карарның 5 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәсен өзү әлеге карарның 3 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 21 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

9. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм http://baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р. Нотфуллин